РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

01 февраль 2024 ел　　Вәрәшбаш авылы　　№ 3

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл жирлеге муниципаль берәмлегендә 2024 елга җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирләү һәм күмү эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының “Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында” 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, "2024 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэфициентын раслау турында" 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә Мослим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 8 370,20 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. 2024 елның 1 февраленнән “Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында” 27.01.2023 елның 1 номерлы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәглүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитеты җитәкчесе**　　**З.З.Галиева**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл жирлеге
Башкарма комитетының
01.02.2024 елның 3нче карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районынын Вәрәшбаш авыл жирлегендә 01.02.2024 елдан жирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4 551,40 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1 558,69 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 2 260,11 |
| **Барлыгы** | **8 370,20** |

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
01.02.2024 елның 3нче карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлегендә 01.02.2024 елдан җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәтнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 1 247,00 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3 382,34 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1 558,69 |
| 5. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 2 182,17 |
| **Всего** | **8 370,20** |